РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ | КАРАР

28.06.2024 | Буа шәһәре | № 3-62

ТР Буа муниципаль районы Советының 2019 елның 22 апрелендәге 9-39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелекне алып бару өчен муниципаль милектә булган җирләрне һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне күп балалы гаиләләргә бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында,

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. ТР Буа муниципаль районы Советының 2019 елның 22 апрелендәге 9-39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль район территориясендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелекне алып бару өчен муниципаль милектә булган җирләрне һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне күп балалы гаиләләргә бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.21 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.21. 1.1 пунктта күрсәтелгән гражданнарга җир кишәрлекләрен бушлай милеккә бирү (тапшыру) турында мәгълүмат әлеге Нигезләмәдә, «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүматны «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру (алу) 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы "Дәүләт социаль ярдәме турында"гы Федераль закон нигезендә башкарыла.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми рәвештә басылып чыккан көннән башлап законлы көченә керә http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов